*Коллектив һәм аның эше*

# ХӘЗИНӘ ЭЗЛӘҮЧЕЛӘР

**Норлат геофизик эшләр идарәсе.** Районда инде ничә еллардан бирле эшләп килгән бу оешманың хезмәте, нинди мәшәкатьләр белән яшәве турында, дөресен әйтик, без күптәннән яза алганыбыз юк. Ә бит 160 тан артык кешене берләштергән бу коллектив гаять әһәмиятле эш башкара, соңгы елларда стабильлеген югалткан экономик мөнәсәбәтләр чорында да таркалмыйча һәм зарланмыйча үз көнен үзе күрергә тырыша. Бүген без газета укучыларга шулар хакында сөйләмәкче булабыз.

## Берсе дә артык түгел

ИДАРӘДӘГЕ партияләр һәм отрядларның исемнәре беренче ишетүгә колакка бөтенләй ят: газокаротаж экспедициясе, гидродинамик тикшеренүләр отряды, инклинометрик отрядлар, перфоратор партияләре һәм башкалар. Боларда, һичшиксез, бик белемле, махсус әзерлекле кешеләр генә эшли алалардыр.

—Соңгысы хак: бездә урамнан кергән теләсә кем эшли алмый, коллективта эшләүчеләрнең күбесе югары һәм махсус белемле,—ди идарәнең баш инженеры Р. Х. Әхмәтшин.—Махсус әзерлекле кеше өчен эш ул кадәр үк башкармаслык димәс идем.

Партия һәм отрядларның исемнәре никадәр генә телне сындырырлык чит булсалар да алар һәммәсе бер максатка: җир ятмаларында нефть һәм газның булу-булмавын тикшерүгә эшлиләр икән. Төрле ысуллар белән, эшнең төрле этапларында шуны тикшерәләр, әзләнәләр, нәтиҗә ясыйлар. Аңлашылганча, бу нәтиҗәләр иң элек НУРБ һәм НГДУга кирәк. Шуңа да идарә эше турыдан-туры әлеге оешмалар белән бәйле, ул заказчыга эшли. Заказчылардан заказ керә икән —отрядлар һәм партияләр өчен ул закон: көнме, төнме, бәйрәмме, ялмы—берни белән санашмыйча юлга чыгалар. Заказ юк икән—никадәр генә тырыш кешеләрдән тормасын, идарә коллективны эш белән тәэмин итүдә кыен хәлдә кала. Соңгы вакытта разведка бораулавы күләме кыскару сәбәпле нәкъ шул кыенлык күзәтелә дә: заказлар саны бермә-бер азая, эш күләме кими һәм безнең карашка анда эшләүчеләрне кыскартмыйча һич чара юк сыман...

Әмма идарә җитәкчелеге әлегә бу кыенлыктан чыгу юлын тапкан. Ничекме? Әлбәттә, эшчеләрне эш күләме белән тәэмин итү бәрабәренә. Берничә отряд Оренбург өлкәсендә эшли, җәйге айларда Көнбатыш Себердә дә заказлар үтәүгә теләп ризалашалар. Аннан алар үзләрендә төзелеш группасы оештыралар. Аның белән махсус техник-төзүче белгечлеге булган Николай Маликов җитәкчелек итә. Әлеге отрядта бер төркем эшчеләр керамзит кирпеч блоклары җитештерәләр.

—Көнгә 200не әзерлибез,—диләр егетләр эшләреннән аерылмыйча гына. Шул ук группаның икенче төркеме авылларда терлекчелек объектлары төзү белән шөгыльләнә. Хәзер, мәсәлән, алар Синдряков исемендәге колхозда амбар коралар.

Тагы бер мөмкинлек—идарә гидрокүтәрткеч белән шәһәрдәге оешмаларга заказ буенча хезмәт күрсәтә. Районда бердәнбер бу кранга эш һәрчак чыгып тора, шулай итеп, бусы да үзенә күрә бер файда бирә.

Аннан тагы бер нәрсә бар. Узган ел 634 нче СМПны геофизикларга тапшырганнар иде. Хәзер, 1 октябрьдән ул ремонт-төзү участогы санала. Гомер бакый артталыктан чыкмаган, проблемалардан арынмаган төзү-монтаж поезды коллективының эш объектлары, заказлары шул ук калды. Әмма аңа тагы бер нәрсә өстәләчәк: киләсе елдан алар идарә өчен кирпеч заводы төзи башлаячаклар. Димәк, янә эш объекты булачак дигән сүз.

Идарәдә эшләүчеләрнең күбесе — яшьләр, уртача 30—35 яшьләр. Бу кеше гомеренең егъылып торып эшли, тормышын җайга сала, балалар үстерә торган чагы. Икенче төрле әйткәндә, материаль тәэмин ителешкә дә, кайгыртуга да иң мохтаҗ чагы. Идарә җитәкчелеге нәкъ шуны аңлап эш итүе белән күп нәрсә ота да. Иң кыен вакытта да биредә китәргә гариза язучылар сирәк, кадрлар даими икән—бу җитәкчелекнең эш стиленә турыдан-туры бәйле. Гадәттә кызулык белән язылган гаризаны биредә салкын канлылык белән кабул итә беләләр, аның иясе белән ачыктан-ачык сөйләшергә вакыт табалар һәм еш кына кешене урынынннан кузгалырга мәҗбүр иткән сәбәп уңай хәл ителерлек булып чыга. Кеше турында кайгыртуга килгәндә дә шулай. КИП инженерлары белән сөйләшүдән дә шул аңлашылды. Румия Рифкатовна Заһретдинова кул астында эшләүчеләрнең дүртесе дә —инде биредә күптәннән эшләүче инженерлар.

—Хатын-кызларга балалар өчен бирелә торган ял иң беренче бездә кертелде. 1 нче сентябрьдә балалары 1 нче класска баручы аналар өчен ял да бездә генә бугай.

—Һәр елны азык-төлеген— карабодай ярмасын итен, онын биреп торалар. Быел да әнә бөртектә, он да тараттылар,—диләр алар берсен-берсе бүлә-бүлә. Соңгысы — быел ярдәмче хуҗалыкларында үстерелгән уңыштан икән. 100 гектар җире, 15 баш мөгезле эре терлеге булган бу хуҗалык белән Николай Николаевич Давыдов җитәкчелек итә. Быел анда карабодай, солы, бодай, азык культуралары үстерелгән. Әле менә өлкәннәр көне уңаеннан да он (теләүчеләргә бөртек), карабодай ярмасы таратылган, соңрак ит тә биреләсе икән. Боларның һәммәсе— кешеләр өчен, алар мәнфәгатен кайгыртып башкарылалар, шуңа замана кыенлыгы тудырган проблемалар алдында кеше үзен япа-ялгыз итеп түгел, терәкле итеп тоя. Ә бу, ышаныгыз, кечкенә нәрсә түгел, кешене коллективка ныклап бәйли торган мөһим нәрсә.



## Эшли белү— төп сыйфат

АЛДАРАК әйтеп үткән идек инде: коллективның зур күпчелеге яшьләрдән тора. Әмма бу идарәдә өлкән буын эшчеләр юк дигән сүз түгел. Алар да бар, геофизик һөнәренә гаиләләре белән береккән семьялар да бар. Хәлиуллиннар өчен, мәсәлән, идарә икенче туган йорт сыман ук кадерле, газиз. Өлкән Хәлиуллин —Радик Абдрахманович— комплекслы партия начальнигы, гаҗәеп тәҗрибәле белгеч. Аның янына теләсә нинди сорау белән барсаң да җавапсыз кала торган түгел, бик мәгълүматлы кеше. Теләсә нинди дәрәҗәдә дә үз һөнәрен яклый да, аның дәрәҗәсен күтәрә дә белә торган ветеран. Әлбәттә, гаилә башлыгындагы мондый һөнәргә мәхәббәте үз йогынтысын ясамый калмаган , улы Ирек армиядән соң шулай ук биредә—7 нче партиядә моторчы булып эшли. Партия начальнигы Шамил Мансурович Камалов үзе дә Лениногорск техникумын тәмамлап, идарә ачылганнан бирле диярлек биредә хезмәт куя торган кеше. Ирек һәм аның кебек яшьләргә кемнән аталарча киңәш алырга дип бер дә аптырап йөрисе юк, өлкәннәр һәммәсе өйрәтү-киңәш бирү ягына килгәндә бик җаваплы карыйлар. Гавриловлар фамилиясе дә идарәдә бик таралган фамилия. Аппаратуралар ремонтлау буенча мастер Иван Ивановичтан башланган династия хезмәт биографиясендә байтак еллар диспетчер булып эшләгән хатыны Надежда Петровна язып калдырган матур хатирәләр дә бар. Хәзер аны машинист булып эшләүче уллары Евгений тулыландыра. Бу гаилә членнары өчен дә тирән җаваплылык, хезмәт сөючәнлек хас. Андыйлар, бәхеткә, байтак.

Әхмәтшиннар, Камышиннар, Кузьминнар, Казанбаевлар, һәм, ниһаять, Ампилоговлар гаиләләре— һәммәсе идарә маркасын югары тотып, эшче намусы белән горурланып эшли һәм яши торганнардан. Шуңа дадыр, геофизикларда дисциплина, эчке тәртип турында сүз бик сирәк кузгатыла. «Кирәк» сүзе —биредә закон, аңа һәр кем берсүзсез буйсына. Геофизик тикшеренүләрне алып баручылар, соңгы нәтиҗәне бирүче КИП инженерлары, хисап хезмәткәрләре, эшчеләр, партияләр — һәммәсе өчен дә ул бер үк дәрәҗәдә мөһим. Шуңа идарә базасында да һәр җирдә тәртип, эшлеклелек. Ремонтчылар цехлары якты, җылы, базада ремонттан чыккан җайланмаларны сынау өчен контроль-тикшерү скважинасы эшләп тора. Эш ысулларының яңаларын гамәлгә кертү мәсьәләсендә дә геофизиклар акрын селкенә диеп булмый. Элек, перфоратор партияләре әлегәчә шартлату ысулы белән эшләсә, хәзер яңа бораулау юлы белән дә хезмәт күрсәтә ала.

Инклинометрик отрядлар авыш скважина ысулын тулысынча үзләштерделәр, инде максатлары —горизонталь скважина белән эшләүгә омтылу. Шуның бәрабәренә партияләр тикшеренүләр күләмен сакларга тырышалар. Ш.М. Камалов партиясе, мәсәлән, 9 айда 892,8 мең сумлык геофизик тикшеренүләр башкарды, Р. А. Хәлиуллин партиясе —590,1 мең сумлык. Ышаныгыз: скважиналарның үткәрүчәнлеге кискен кимегәндә, болар начар саннар түгел.

(Дәвамы бар).

**С. ХӘЙРУЛЛИНА.**

# Бәхетле очраклылык

Тормышта үз юлын һәр кеше үзенчә таба: кемдер бала чагыннан ук педагог булырга хыяллана һәм шуңа ирешә дә, кемдер актер булырга тели, әмма бик яхшы табиб булып китә, ә кемдер үз һөнәрен очраклы рәвештә генә таба, ләкин барыбер үз эшенең остасына әверелә.

Минния ишле тату гаиләдә үсә. Монда зуррак балалар кечерәкләрен караша, шуңа күрә аларны балалар бакчасына тәрбиягә бирергә туры килми. Минниянең балалар бакчасы тәрбиячесе һөнәрен күз алдына да китерә алмавы шулай ук гаҗәп түгел. Ул монда олы апасы эшләгәнгә генә килә. Килә һәм үзенең язмышын гомерлеккә шушы сабыйлар белән бәйли. Ике ел няня булып эшли, аннан соң ясле группасына тәрбияче итеп күчерүләрен сорый. Аның бөтен сәләте, омтылышы шунда ачыла да инде. Балалар белән эшләгәндә ягымлы һәм кайгыртучан булу гына җитми, бик күп балалар җырларын, әкиятләрен өйрәнергә, рәсем ясый һәм саннар әвәли белергә, һәм моңа балаларны да өйрәтергә тиешсең. Минния Вәлиҗановна Мәүлетова ике бала анасы булуына карамастан, эштән аерылмыйча, Бөгелмә педучилищесының мәктәпкәчә яшьтәгеләр өчен тәрбиячеләр хәзерләүче бүлеген тәмамлады. Беренче чыгарылышын мәктәпкә озатканына да күп вакыт узды инде. Менә җиде ел буе ул олы түземлелек белән сабыйларны халык әкиятләрен тыңларга һәм аңларга өйрәтә, тирә-юньдәге тормыш белән кызыксыну һәм ихтирам тәрбияли, агачны яндырып рәсем ясарга, йомшак уенчыклар тегәргә өйрәтә, ягъни балаларның сәләтләрен һәръяклап үстерү өчен тырыша. 1992—93 уку елында ул балаларның яңа группасын кабул итте. Монда бөтен тәрбия процессы татарча гына алып барылачак. Группадагы 27 баланың 4 се— милләте буенча рус һәм чувашлар. Балалар һәммәсе дә бик матур итеп дөрес интонация белән татарча сөйләшәләр, русча да аңлаша алалар.

Минния Сәлимҗановна янәдән эзләнә, иҗат итә һәм сабыйларның бөтен гомер буена сузылачак үсешенә нык лы нигез сала. Аңа бу игелекле эшендә зур уңышлар телисе килә. Үзе дә, кулы астындагы сабыйлар да, гаиләсе һәм хезмәттәшләре дә Минния белән янәшә һәрвакыт бәхетле булсыннар.

**А. ХӘМӘТВӘЛИЕВА,**
2 нче балалар бакчасы мөдире.

